РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Уразаевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района
ул. Н.Бадертдинова, д. 35,
Азнакаевский район, с.Уразаево,
423303,
тел./факс (885592)43-5-55
E-mail: Uraz.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Уразай авыл җирлеге
башкарма комитеты

Н.Бадертдинов ур., 35 йорт, Азнакай
районы, Уразай авылы, 423303
тел./факс (885592)43-5-55
E-mail: Uraz.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**31 гыйнвар 2023 ел** **№ 4**

2023 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хокүмәтенең 2023 елнын 30 гыйнварындагы 119 номерлы карары нигезендә «2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2023 елның 01 февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 7 793,48 сум (җиде мең җиде йөз туксан өч сум 48 тиен) күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә.

2. “2022 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында” 2022 елның 28 гыйнварындагы №5 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге башкарма комитетының карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.

tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo. tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык: А.М.Шэрифуллина

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта

31 гыйнвар 2023 ел №4

2023 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлектә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 3693,48 |
| 2 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1500,00 |
| 3 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2600,00 |
| **4** | **Барлыгы** | **7793,48** |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 2 нче кушымта

31 гыйнвар 2023 ел №4

2023 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлектә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Кәфенләү | 1400,00 |
| 2 | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2293,48 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1500,00 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2600,00 |
| **5** | **Барлыгы** | **7793,48** |